| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2017 елның 03 мае** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1217** |

2017 елның II кварталына салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән, Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү методикасына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары буенча 2017 елның II кварталына торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясе турында» 2017 елның 13 апрелендәге 708/пр номерлы боерыгы белән, шулай ук Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның икенче кварталына гражданнарны аз keремле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 164 537 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 1 482 138 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 1 905 606 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 540 808 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен 1.1.5 - 3 176 010 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 3 811 212 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган өчен гаилә өчен - 4 446 414 сум;

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 12 666,83 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 8 060,71 сум;

1.2.3. өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 6 909,18 сум.

2. «ЗМР Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

**2017 елның II кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. **Базар бәясенең хисап күрсәткече**

**СЖ= НП*РС* РЦ, биредә**

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган 1 кв.м. мәйданның уртача хисап базар бәясе (2017 елның икенче кварталына - 35 289 сум)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 35 289 *33= 1 164 537

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *42= 1 482 138

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *18*3= 1 905 606

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *18*4= 2 540 808

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *18*5= 3 176 010

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *18*6= 3 811 212

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=35 289 *18*7= 4 446 414

2. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ {1-[(1+ПС) - КП]/ (0,3*РС), биредә**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер ай эчендә процент ставкасы (14/12);

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кеременә карата нисбәте;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД=(0,7*1 164 537*1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*1)= 12 666,83

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*1 482 138*1,16) / {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*2) = 8 060,71

в) өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*1 905 606*1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*3)= 6 909,18

г) дүрт кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*2 540 808*1,16)/ {1-[(1+1,16) - 250]/ (0,3*4)= 6 909,18

« ЗМР торак сәясәте департамент»
МКУ җитәкчесе Ж.Е. Багабиева